ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 18 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2023, № 92 (I өлеш), № 95 (I өлеш); 2024, № 16 (I өлеш), № 28 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) беренче абзацта «Реабилитацияләнгән гражданнарга» сүзләрен «1. Реабилитацияләнгән гражданнарга» сүзләренә алмаштырырга;

2) түбәндәге эчтәлекле 2 пункт өстәргә:
«2. Репрессияләр аркасында торак урыннарын югалткан реабилитацияләнгән гражданнар, Татарстан Республикасы территориясендәге элекке яшәү урынына (аларга карата репрессия кулланылганга кадәр яшәгән җирләренә һәм торак пунктларга) кире кайткан очракта, һәм аларның гаилә әгъзалары торак урыннарга мохтаҗ дип таныла. Күрсәтелгән затлар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә исәпкә алына һәм торак урыннар белән тәэмин ителә. Бу хокук шулай ук аларның гаилә әгъзаларына һәм репрессияләнгән затлар

белән аларга карата репрессия кулланылганга кадәр бергә яшәгән башка туганнарына, шулай ук иректән мәхрүм итү урыннарында, сөргендә, куып җибәрелгән урында, махсус яшәү урынында туган балаларына кагыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 25 апрель
№ 25-ТРЗ